Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында яшел үсентеләрне саклау һәм карап тоту кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Яшел хуҗалыкны һәм бакча-парк төзелешен алып бару буенча төп таләпләрне гамәлдәге стандартларга, нормаларга һәм кагыйдәләргә туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 44 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 11 октябрендәге 596 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында яшел үсентеләрне саклау һәм тоту Кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

V өлешнең 13 пунктында:

9 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) автомашиналар, мотоцикллар, башка транспорт төрләренең (гомуми файдаланудагы транзит юлларыннан һәм объектны эксплуатацияләү өчен билгеләнгән юллардан тыш) узуы һәм туктау урыны;»;

11 пунктны төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнарына үзләренең муниципаль хокукый актларын күрсәтелгән Кагыйдәләргә туры китерергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе М.Р. Гафаров